# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы
Мортыштамак авыл җирлеге Колмәт авылында
2026 елда гражданнарның үзара салымын кертү турында

2025 елның 13 ноябре № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында "2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елнын 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылында гражданнар җыены

Карары:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Мортыштамак авыл җирлегенең Колмәт авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган, 1 нче төркем инвалидларыннан, 90 яшькә җиткән ялгыз өлкән яшьтәге гражданнардан, вакытлы хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, көндезге уку йортлары студентларыннан, Украина территориясендә махсус хәрби операциядә катнашучылар, аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 2026 елда 500 сумнан үзара салым кертергә:

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1) урамнарда яктырту челтәрләрен ремонтлау, урамнарны яктырту җайланмасы (лампалар, энергияне сак тоту яктырткычлары, электр товарлары сатып алу һәм урнаштыру, урам яктырткычларын ремонтлау һәм аларга хезмәт күрсәтү, шартнамә буенча эшләр өчен түләү),
2) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмиятле автомобиль юлларын карап тоту (ягулык-майлау материалларын сатып алу, юлларны кардан чистарту, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү),
3) халыкның күпләп ял итү урыннарын (спорт мәйданчыкларын) ремонтлау, янәшәсендәге территорияләрне төзекләндерү (ГСМ бензин сатып алу, триммер өчен запас частьләр сатып алу, үләннәр чабып алу, шартнамә буенча хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)
4) Колмәт торак пунктында 2026 ел өчен үзара салым акчаларыннан янгынга каршы су чыганаклары белән тәэмин итәргә.
5) традицион җирләү урыннарын төзекләндерү, (шартнамә буенча эшләр өчен түләү);3. Әлеге карарны Мортыштамак авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгән көннән 7 көн эчендә.

Сарман муниципаль район
Мортыштамак авыл җирлеге
башлыгы: Хафизов И.И.